| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.08.2025 ел Баулы шәһәре №113

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 сентябрендәге 169 номерлы карары белән расланган, муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына (2023 елның 15 февралендәге 37 номерлы, 2024 елның 12 февралендәге 17 номерлы, 2024 елның 18 ноябрендәге 167 номерлы, 2025 елның 27 февралендәге 23 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

"Россия Федерациясе Җир кодексына һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" Федераль законның 34 статьясындагы 7 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында" 2024 елның 28 декабрендәге 538-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 сентябрендәге 169 номерлы карары белән расланган, муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына (2023 елның 15 февралендәге 37 номерлы, 2024 елның 12 февралендәге 17 номерлы, 2024 елның 18 ноябрендәге 167 номерлы, 2025 елның 27 февралендәге 23 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

2 «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендә:

2.8.2.1.пунктында:

3) пунктчада «йә» сүзләреннән соң «җир кишәрлеген федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезендә беренче чиратта яисә чираттан тыш сатып алуга

хокукы булган бакчачылык яисә яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәттә катнашу (әгъзалык) хокукына ия булмаган граждан йә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.18 статьясы нигезендә җир кишәрлеге сатып алуга (әгәр мондый җир кишәрлеге бакчачы булса), шулай ук искәрмә нигезендә җир кишәрлеге сатып алуга хокуклы» сүзләрен өстәргә;»;

13) пунктчада «хуҗалык» сүзеннән соң «торак пунктлар чикләрендә» сүзләрен өстәргә;

16 пунктчада) «иң чик» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров